**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 декабрендәге 4706 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 30 декабрендәге 7660 номерлы «Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан шәһәре территориясендә бердәм парковка киңлеге эшчәнлеген тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль законнарга, 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 18 апрелендәге 2096 номерлы «Казан шәһәрендә парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм алардан файдалану, шул исәптән түләүле нигездә файдалану тәртибе турында»гы карарына таянып, Казан шәһәренең юл хәрәкәте иминлеге комиссиясе карарлары, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2025 елның 11 ноябрендәге 01-02-03/07-25кчс номерлы «2025/2026 еллар кышкы чорында автомобильләрнең һәм шәһәр электр транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү буенча Казан шәһәре комитетларының, идарәләренең, учреждениеләренең һәм оешмаларының эш планын («Буран» планын) раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Югары судының 2022 елның 6 сентябрендәге 33а-13520/2022 номерлы апелляция билгеләмәсе нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 30 декабрендәге 7660 номерлы «Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 16 февралендәге 734, 2015 елның 4 июнендәге 2284, 2015 елның 2 октябрендәге 3598, 2016 елның 22 гыйнварындагы 148, 2016 елның 4 апрелендәге 1311, 2016 елның 27 апрелендәге 1806, 2016 елның 29 июнендәге 2621, 2016 елның 17 октябрендәге 4156, 2016 елның 2 декабрендәге 4908, 2017 елның 31 гыйнварындагы 162, 2017 елның 23 июнендәге 2270, 2017 елның 24 октябрендәге 4269, 2017 елның 4 декабрендәге 4964, 2018 елның 22 июнендәге 3657, 2018 елның 18 июлендәге 4032, 2018 елның 18 сентябрендәге 4987, 2018 елның 4 декабрендәге 6132, 2019 елның 16 апрелендәге 1404, 2019 елның 26 июлендәге 2714, 2019 елның 19 сентябрендәге 3326, 2019 елның 13 ноябрендәге 4029, 2020 елның 9 октябрендәге 2918, 2020 елның 26 ноябрендәге 3464, 2021 елның 28 гыйнварындагы 199, 2021 елның 18 мартындагы 635, 2021 елның 5 маендагы 1121, 2021 елның 5 июлендәге 1648, 2021 елның 28 июлендәге 1860, 2021 елның 9 сентябрендәге 2260, 2021 елның 21 октябрендәге 2736, 2021 елның 11 ноябрендәге 2960, 2021 елның 22 декабрендәге 3433, 2022 елның 2 февралендәге 331, 2022 елның 17 июнендәге 1856, 2022 елның 6 июлендәге 2135, 2022 елның 21 октябрендәге 3601, 2023 елның 16 гыйнварындагы 77, 2023 елның 13 июлендәге 1972, 2023 елның 2 октябрендәге 2907, 2023 елның 1 декабрендәге 3788, 2023 елның 29 декабрендәге 4418, 2024 елның 13 февралендәге 494, 2024 елның 7 маендагы 1945, 2024 елның 1 августындагы 3221, 2024 елның 20 сентябрендәге 3991, 2024 елның 2 ноябрендәге 4626, 2025 елның 4 апрелендәге 1029, 2025 елның 23 маендагы 1614, 2025 елның 31 июлендәге 2514, 2025 елның 26 августындагы 2715, 2025 елның 21 ноябрендәге 4085 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. түбәндәге эчтәлекле 5(1) пункт өстәргә:

«5(1). Казан шәһәренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе боерыгы нигезендә «Буран» планы кертелгәндә әлеге чорга муниципаль парковкаларда (парковка урыннарында) транспорт чараларын урнаштыру эше түләүсез башкарыла дип билгеләргә»;

1.1.2. 1 номерлы кушымтада:

1.1.2.1. 75 нче юлда «74» санын «61» санына алыштырырга;

1.1.2.2. әлеге карарның кушымтасы нигезендә редакцияләп, 257-259 нчы юллар өстәргә;

1.1.2.3. «БАРЛЫГЫ» юлында «14159» санын «14489» санына алыштырырга;

1.1.3. 3 номерлы кушымтада 2.5.4 пунктчадагы «яки аларны идентификацияләүне кыенлаштыра торган» сүзләреннән соң «, транспорт чарасын үз файдалануы өчен әзерләгәндә аны әйләнешкә чыгарган көннән алып, транспорт чарасын Россия Федерациясе территориясенә бер елдан артык вакытка вакытлыча керткән көннән алып яки элегрәк Россия Федерациясендә дәүләт исәбендә тормаган, шул сәбәпле дәүләт теркәү билгеләре булмаган транспорт чарасына хуҗа булу хокукларын алган көннән алып ун көн эчендә дәүләт теркәү исәбенә куелмаган транспорт чараларыннан тыш» дигән сүзләр өстәргә;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) юл хәрәкәтендә катнашучыларга юл хәрәкәтен оештырудагы һәм муниципаль парковкалардан файдалану кагыйдәләрендәге үзгәрешләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль медиаресурслар аша хәбәр итәргә **тәкъдим итәм**.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөклим.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 26 декабрендәге
4706 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында түләүле муниципаль парковкалар (парковка урыннары) реестры**

| № т/б | Урнашу урыны | Машина урыннары саны | Парковка урыннарыннан 1 сәгать дәвамында файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| «257 | Четаев урамы (урамның ике ягы да, А.Бичурин урамы киселешеннән Ф.Әмирхан урамы киселешенә кадәр) | 16 | 30 сум |
| 258 | Беломорская урамы (урамның җөп ягы, Ленинград урамы киселешеннән Чапаев урамы киселешенә кадәр) | 133 | 30 сум |
| 259 | Ямашев проспекты (Ямашев проспектындагы 71А, 73А йортлары янындагы территория) | 194 | 30 сум» |